***МИССИОНЕРСКИЙ ЛИСТОК***
***КРЯШЕНСКАЯ ДУХОВНАЯ МИССИЯ (http://www.missiakryashen.ru)***

# ХРИСТОСНЫҤ БАХЕТЛЕКЛЯР БОЙОРОГО

**1.Жыуаш кюҥеллеляр бахетле: Кюк Падшалыгы аларныкы шул.**

Ўзен ўзе кешедян начарга куйыб, кечегя куйыб тороучылар бахетле, бу дӧньядян кючкяч, алар жомакка, Кюк Падшалыгына изгеляр катына урыннашырлар.

**2.Жылаучылар бахетле: алар сӧйӧнӧч табарлар шул.**

Жазыклары ӧчӧн кайгырыб, кӧйӧнӧб, ўкенеб жылаучыларнын жазыклары кичерелер, алар Кюктя мянге сӧйӧнӧчтя булырлар.

**3. Сабырлыклылар бахетле: аларга жир теяр шул.**

Кешенен ачыуын китермейче, кешегя ачыуланмыйчы, тюзеб тороучылар Кюктяге жомакка кереб мянгегя сӧйӧнӧрляр.

**4. Дӧрӧслӧккя ачыгыб, сыусаб тороучылар бахетле: алар туклаҥырлар шул.**

Турылык белян тороб, кешегя жакшылык кыларга тырышыучылар, изге торорга тырышыучылар, калдык сораудa дӧрӧскя чыгарылырлар.

**5. Изгелеклеляр бахетле: алар жарлыкаулы булырлар шул.**

Жарлыларга, мескеннярга, чирлелярга кюҥелдян булышыучыларга Ходай изгелек кылар, жазыкларын кичерер.

**6. Таза кюҥелляр бахетле: алар Алланы кюрерляр шул.**

Жазыклы итя торган бозок уйларны кюҥелдян чыгарыб, арыу уй тотоучылар, няпес белян керяшеўчеляр бу тормошта да Алланы кюрерляр. Алла аларга килеб урыннашыр.

**7. Татыуландырыучылар бахетле: алар Алла уллары диб аталырлар шул.**

Бер берсеня дошманнык кылыучыларны, ўбкя тотоучыларны татыуландырыучылар Кюктя мянге сӧйӧнӧчтя булырлар.

**8. Дӧрӧслӧк ӧчӧн кыуылыучылар бахетле: Кюк Падшалыгы аларныкы шул.**

Гадел тормош белян, сауаблы тормош белян торганнары ӧчӧн рянжетелгян, кимсетелгян кешеляр, Кюккя изгеляр катына урыннашырлар.

**9. Ӓгяр Минем хакымда сезнен ӧстян жалганнаб, тӧрлӧ усал сюз ӓйтсяляр, сезне хурласалар, сезне кыусалар, сез бахетле. Сӧйӧнӧгӧз, кыуаныгыз: сезгя Кюктя теясе сауаб бик оло шул.**

Ходай Иисус Христос хакына ӧсляреннян тӧрлӧчя жалганнаб ӓляклягянгя тюзеўчеляр, кысанныкка, малдан жазыуга, кыйналыб жараланыуга, ўтерелеўгя тюзеўчеляр Кюктя мянге рахятлектя булырлар. Аларга Кюктя сӧйӧнӧч бик оло булыр.

*Ӧй-хужалыгында кулланмаска*
*В хозяйственных целях не использовать!*